ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2021 г. с. Муслюмово № 25

**Мөслим муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре һәм авыл җирлекләре арасында XXXI кышкы Спартакиада уздыру турында**

Халык арасында физик культураны һәм спортны, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, спорт осталыгын арттыру, спорт төрләре буенча җыелма команданы туплау максатларында, муниципаль район Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре һәм авыл җирлекләре арасында XXXI кышкы Спартакиаданы 2021 елның 6 февраленнән 27 февраленә кадәр үткәрергә.
2. Расларга: авыл җирлекләре арасында XXXI кышкы Спартакиада Нигезләмәсен (1 нче кушымта); район оешмалары һәм предприятиеләре арасында XXXI кышкы Спартакиада Нигезләмәсен (2 нче кушымта).
3. Мөслим муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары җитәкчеләренә һәм авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:
   - команда әзерләргә;
   - команданың катнашуын оештырырга;
   - ярышларга бару өчен транспорт белән тәэмин итәргә;
   - команда әгъзаларының туклануын оештырырга.
4. «Финанс-бюджет палатасы» МКУга, каралган финанс ассигнованиеләре кысаларында, чараларны вакытында финанслауны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә (3 нче кушымта).
5. «Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.Т. Демидовка, районның гомуми урта һәм төп белем бирү мәктәпләре директорларына:
   - Командаларның тренировкалары өчен спорт залларын әзерләргә һәм кирәкле спорт инвентарьлары бирергә.
6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районы бүлеге башлыгы Р.Р. Гатауллинга ярышлар вакытында хокук тәртибен тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
7. «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы Д.Н. Якуповка һәм «Спорт мәктәбе» МБУ директоры И.М. Фазлыевка беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен һәр ярышка медицина персоналын тәэмин итәргә.
8. Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы И.Р. Җаббаровка:
   - Спартакиаданы үткәрү буенча гомуми җитәкчелекне оештырырга;
   - Спорт ярышлары судьяларын оештырырга һәм тәэмин итәргә;

- Ярышларда җиңүчеләргә грамоталар һәм бүләкләр әзерләргә.

9. «Спорт мәктәбе» МБУ директоры И. М. Фазлыевка, «Спорт чаралары дирекциясе» директоры М. А. Байрхановка чаңгы трассаларын, керү юлларын, автостоянкаларны әзерләргә.

10. Территориаль үсеш бүлеге башлыгы Ф.Ф. Вәлиевка ярышларны уздыру вакытында азык-төлек продуктлары сатуны оештырырга тәкъдим итәргә.

11. «Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы И.Ф Салихҗановка чараларның музыкаль бизәлешен тәэмин итәргә.

12. «Татмедиа» ААҖ филиалы – «ММҮ» ДУ директоры Р.Р. Афзаловага учреждениеләрнең, предприятиеләрнең һәм авыл җирлекләренең спартакиадага әзерлек барышын, ярышлар нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы И.Р. Җаббаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.А. Ильясов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының

2021 елның «____»
гыйнварындагы
____ нче карарына 1 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре арасында XXXI кышкы Спартакиада үткәрү турында Нигезләмә**

**1. Максатлар һәм бурычлар.**

- халык арасында спорт төрләрен популярлаштыру;
- спорт осталыгын күтәрү;
- иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

**2. Үткәрү вакыты һәм урыны.**

Ярышлар 2021 елның **7 февраленнән 27 февраленә кадәр** Мөслим авылында үткәрелә. Киңәшмә 2021 елның 25 гыйнварында 14.00 сәгатьтә муниципаль район Советының актлар залында узачак (веб-камера буенча).

**3. Ярышларны үткәрү шартлары һәм катнашучыларга керүгә рөхсәт.**

Авыл җирлекләре командасы 18 яшькә җиткән гражданнардан, әлеге авыл җирлегендә эшләүчеләрдән һәм студентлардан туплана. Команда әгъзалары паспортында күрсәтелгән җирдә яшәргә яки туган урынга ия булырга яисә әлеге авыл җирлегендә төп эш урынына ия булырга тиеш.

Бер спортчы барлык ярышларда да чикләүләрсез чыгыш ясарга хокуклы. Әгәр ярышларда ялган затлар катнашса, команда җиңелүче дип санала һәм ярышларның бу төре буенча соңгы урынны били. Оешма-предприятиеләр, авыл җирлекләре арасында XXXI кышкы спартакиадада «Спорт мәктәбе» МБУ, «Юность» спорт-сәламәтләндерү комплексы (Спорт чаралары дирекциясе), «Форпост» спорт оешмалары хезмәткәрләре катнаша алмый.

**Спорт төрләре буенча протестлар ярыш вакытында һәм (яки) ярыш төре тәмамланганнан соң 5 минут эчендә Баш судья исеменә язма рәвештә тапшырыла.**

**Спартакиаданы оештыручыларга һәм хөкемдарларга карата тупас мөнәсәбәт, норматив булмаган лексика кулланган очракта, команда яки уенчы бөтен уен ахырына кадәр дисквалификацияләнәчәк.**

Ярышларда катнашучыларның үзләре белән түбәндәгеләр булырга тиеш:

- авыл җирлеге җитәкчесе раслаган гариза;
- паспорт (оригинал!);
- хезмәт кенәгәсе (яки таныкланган күчермәсе).

Документларсыз спортчы ярышларда катнашмый. Юл йөрү һәм туклану командировкага баручы оешмалар хисабына башкарыла.

**4. Ярышлар белән җитәкчелек итү.**

Ярышларны үткәрүгә гомуми җитәкчелек муниципаль район Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге тарафыннан башкарыла.

***Ярышларны уздыру түбәндәгеләргә йөкләнә:***

**«Спорт чаралары дирекциясе», «Спорт мәктәбе» МБУ** – судьялар составын оештыру, чаңгы трассаларын әзерләү.
**«Мөслим ҮРХ» ДАССОсы һәм «Спорт мәктәбе» МБУ** – беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен һәр ярышка медицина персоналы тәэмин итү;
**Авыл җирлекләре башлыклары** – XXXI кышкы спартакиадага командаларны туплау һәм катнаштыру;
**«Спорт чаралары дирекциясе»** – авыл җирлекләре (зоналар) арасында кышкы спартакиаданы ачу һәм уздыру вакытында музыкаль-күңел ачу программасы тәкъдим итү; җиңүчеләргә Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге белән бергә тантаналы рәвештә бүләкләр тапшыруны оештыру;
**Мәгариф идарәсе - мәктәп директорлары, физик культура укытучылары** ярышларда катнашалар һәм авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә кышкы спорт спартакиадасында катнашу өчен командалар туплауны оештыралар.
**«Форпост» –** ярышлар вакытында куркынычсызлыкны тәэмин итү.
**«МРҮ» ДУ** – массакүләм мәгълүмат чараларында ярышлар барышын һәм нәтиҗәләрен яктырту.

## 5. Зоналар буенча ярышлар үткәрү программасы һәм тәртибе:

***Ярышлар Олимпия системасы буенча үткәрелә.*** *Барлык ярышлар да бинадан тыш үткәрелә. Ярышлар вакыты оештыру комитеты тарафыннан килештерелә (һава торышы шартлары белән бәйле).*

## СПАРТАКИАДАНЫ АЧУ

**Үткәрү вакыты: 2021 елның 7 феврале.**
9:00 сәг. – спартакиаданы ачу.
**Үткәрү урыны: «Кояшлы Ык» яр буе (Чаңгы базасы)**

**<u>Ярыш төрләре:</u>**
- биатлон. Катнаш эстафета (2 хатын-кыз + 2 ир-ат, хатын-кызлар –1 км, ир-атлар –1 км);
- киез итекләрдә футбол (Валенкобол);
- аркан тарту: (ир-атлар һәм хатын-кызлар);
- Шорт-Трек (эстафета 2 ир-ат + 1 хатын-кыз, ир-атлар – 800 м, хатын-кызлар – 400 м).

## БИАТЛОН

**Үткәрү вакыты: 2021 елның 7 феврале.**
**Үткәрү урыны:** «Кояшлы Ык» яр буе
**БИАТЛОН** Катнаш эстафета (2 хатын-кыз + 2 ир-ат, хатын-кызлар – 1км, ир-атлар – 1км) – «Кояшлы Ык» яр буе. Биатлон эстафетасында беренче катнашучылар судья командасыннан соң, катнашучы командалар санына карап, «бергә яисә 30 секунд вакыт интервалы» белән старт ала. Билгеле бер дистанция узганнан соң (450 метр) һәр спортчыга басып биш мишеньга ату кирәк булачак

(мишень диаметры 10 см, ату дистанциясе 10 метр). Тидерә алмаган очракта өч өстәмә патрон кулланырга мөмкин. Ярышлар барышында спортчыларга түгәрәк мәйданны кисү, бер-берсенә аңлы физик йогынты ясау тыела. Биатлон кагыйдәләре катнашучыларга шулай ук чит мишеньгә атуны тыя. Спортчының чит мишеньгә төгәл эләгүе тидерә алмау дип санала. Ярышның җиңүчесе булып дистанциядә иң яхшы вакыт күрсәткән команда танычла. Пневматик винтовканы (бер разрядлы) команда үзе белән алып килә.

### Киез итекләр футболы
### (ВАЛЕНКОБОЛ)

**Үткәрү вакыты: 2021 елның 14 феврале**
**Үткәрү урыны: «Юность» спорт-сәламәтләндерү комплексы**
**ВАЛЕНКОБОЛ** Команда составы: 5 уенчы (4 уенчы, 1 капкачы)+ запас уенчылар. Ярышлар җирәбә салу буенча үткәрелә. Капкачы тупны ыргытканда мәйданның үз яртысыннан чыгарырга тиеш түгел. Әгәр туп капкачы тарафыннан мәйданчыкның икенче яртысына ташланса, туп көндәш командасына күчә.

### АРКАН ТАРТУ
### (ир-атлар һәм хатын-кызлар)

**Үткәрү вакыты: 2021 елның 21 феврале**
**Үткәрү урыны:** УСЗ керү юлы янында (универсаль спорт залы).
**АРКАН ТАРТУ (ир-атлар):**
Команда составы: 5 кеше. Командаларның гомуми авырлыгы 450 кг.га кадәр. Командалар арасында ярыш өч омтылыштан тора. Командаларның берсе ике омтылышта җиңү яулаган очракта, өченчесе үткәрелми. Һәр омтылыштан соң командалар урыннар белән алыша һәм ял итә (ике минуттан да артык түгел).

**АРКАН ТАРТУ (хатын-кызлар):**
Команда составы - 5 кеше. Командаларның гомуми авырлыгы 400 кг.га кадәр. Командалар арасында ярыш өч омтылыштан тора. Командаларның берсе ике омтылышта җиңү яулаган очракта, өченчесе үткәрелми. Һәр омтылыштан соң командалар урыннар белән алыша һәм ял итә (ике минуттан да артык түгел).

### ШОРТ-ТРЕК

**Үткәрү вакыты:** 2021 елның 21 феврале
**Үткәрү урыны: «Юность» спорт-сәламәтләндерү шугалагы**
**Шорт-трек** (Эстафета: 2 ир-ат + 1 хатын-кыз) ир-атлар - 800 м, хатын-кызлар – 400 м.

### СУПЕРФИНАЛ

**Үткәрү урыны:** «Юность» спорт-сәламәтләндерү комплексы, «Спорт мәктәбе» МБУ (универсаль спорт залы), Чаңгы базасы.

**Үткәрү вакыты:** 27.02.2021 ел 9:00 сәг.

**СУПЕРФИНАЛ:** оешмалар, предприятиеләр һәм авыл җирлекләре арасында гомумкоманда зачетында 1 урынны алган командалар катнашачак. Ярышларның барлык төрләре дә бер көнне узачак. Суперфиналда барлыгы 5 спорт төре узачак.

**Болар – биатлон, киез итекләрдә футбол, аркан тарту (хатын - кызлар һәм ир-атлар), шорт-трек.**

**Әлеге нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора.**

Белешмәләр өчен телефон: 2-59-48

**Гариза үрнәге**
**Мөслим муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре һәм авыл җирлекләре арасында XXXI кышкы спартакиадада катнашучы**
**__________________________ командасы.**
**__________________________ (спорт төре).**

«___» ____________2021 ел.
Мөслим

| **№** | **Ф.И.О. (тулысынча)** | **Туган елы** | **Эш урыны** | **Табиб визасы** | **Табиб имзасы** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |

Рөхсәт бирелде: ______________ кеше.
Табиб: ______________.

Команда вәкиле _______ /________/
Учреждение башлыгы ____________ /_______________/

1.2 кушымта

**А в ы л җ и р л е к л ә р е а р а с ы н д а**
**X X X I к ы ш к ы с п а р т а к и а д а**
**о ч к о л а р ы н и с ә п л ә ү**
**Т А Б Л И Ц А С Ы**

| Урын – очко | Урын – очко | Урын – очко |
|---|---|---|
| 1 - 80 | 8 - 51 | 15 - 37 |
| 2 - 75 | 9 - 48 | 16 - 36 |
| 3 - 70 | 10 - 45 | 17 - 35 |
| 4 - 65 | 11 - 43 | 18 - 34 |
| 5 - 60 | 12 - 41 | 19 - 33 |
| 6 - 57 | 13 - 39 | 20 - 32 |
| 7 - 54 | 14 - 38 | 21 - 31 |

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының

2021 елның «____»
гыйнварындагы
____ нче карарына 2 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре арасында XXXI кышкы Спартакиада үткәрү турында Нигезләмә**

## 1. Максатлар һәм бурычлар.

- халык арасында спорт төрләрен популярлаштыру;
- спорт осталыгын күтәрү;
- иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

## 2. Үткәрү вакыты һәм урыны.

Ярышлар 2021 елның 6 февраленнән 27 февраленә кадәр Мөслим авылында үткәрелә. Киңәшмә 2021 елның 25 гыйнварында 14.00 сәгатьтә муниципаль район Советының актлар залында узачак.

## 3. Ярышларны үткәрү шартлары һәм катнашучыларга керүгә рөхсәт.

Мөслим районы **оешмалары, предприятиеләре, мәктәпләре** командасы әлеге оешмада һәм аның филиалларында, бүлекчәләрендә хезмәт шартнамәсе буенча даими нигездә эшләүче хезмәткәрләрдән туплана. Оешма-предприятиеләр, авыл җирлекләре арасында XXXI кышкы спартакиадада «Спорт мәктәбе» МБУ, «Юность» спорт-сәламәтләндерү комплексы (Спорт чаралары дирекциясе), «Форпост» спорт оешмалары хезмәткәрләре катнаша алмый.

Команда әгъзалары Мөслим муниципаль районында яшәргә тиеш. Мөслим районында даими нигездә эшләүче, әмма пропискасы булмаган чит шәһәрләрдән килгән оешма җитәкчеләре ярышларга кертеләләр.

Бер спортчы барлык ярышларда да чикләүләрсез чыгыш ясарга хокуклы. Бер команда өчен чыгыш ясаган спортчы башка команда өчен катнашырга хокуклы түгел. Мөслим муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре арасында XXXI кышкы Спартакиада вакытында катнашкан оешма, предприятие хезмәткәрләре үз авыл җирлеге командасы өчен катнашырга хокуклы түгел. Әгәр команда суперфиналга чыкмаса, оешма яки предприятие өчен катнашкан хезмәткәр, үзенең авыл җирлеге өчен пропискасы булганда яисә паспортында әлеге җирлектә туган урыны турында тамга куелган очракта катнаша ала.

Гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Мөслим политехника техникумы студентлары, учреждениеләрдә практика үтүчеләр ярышларга кертелмиләр. Әгәр ярышларда ялган затлар катнашса, команда җиңелүче дип санала һәм ярышларның бу төре буенча соңгы урынны били.

Мөслим районы Росгвардия хезмәткәрләре Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районы бүлеге командасы өчен чыгыш ясый.

**Спорт төрләре буенча протестлар ярыш вакытында һәм (яки) ярыш төре тәмамланганнан соң 5 минут эчендә Баш судья исеменә язма рәвештә тапшырыла.**

**Спартакиаданы оештыручыларга һәм судьяларга карата тупас мөнәсәбәт, норматив булмаган лексика кулланган очракта, команда яки уенчы бөтен уен ахырына кадәр дисквалификацияләнәчәк.**

Ярышларда катнашучыларның үзләре белән түбәндәгеләр булырга тиеш:

- учреждение җитәкчесе раслаган гариза;
- паспорт (оригинал);
- хезмәт кенәгәсе (оригинал).

Документларсыз спортчы ярышларда катнашмый.

Юл йөрү һәм туклану командировкага баручы оешмалар хисабына башкарыла.

## 4. Ярышлар белән җитәкчелек итү.

Ярышларны үткәрүгә гомуми җитәкчелек муниципаль район Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге тарафыннан башкарыла.

***Ярышларны уздыру түбәндәгеләргә йөкләнә:***

**«Спорт чаралары дирекциясе», «Спорт мәктәбе» МБУ** – судьялар составын оештыру, чаңгы трассаларын әзерләү. Кышкы спартакиаданы ачу һәм уздыру вакытында музыкаль-күңел ачу программасы тәкъдим итү; җиңүчеләргә Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге белән бергә тантаналы рәвештә бүләкләр тапшыруны оештыру;

**«Мөслим ҮРХ» ДАССОсы һәм «Спорт мәктәбе» МБУ** – беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен һәр ярышка медицина персоналы тәэмин итү;

**Районның барлык милек формасындагы оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләре –** командаларны туплау һәм XXXI кышкы спартакиадада катнашу;

**Мәгариф идарәсе** – мәктәп директорларын, физик культура укытучыларын ярышларда катнаштыру һәм кышкы спартакиадада катнашу өчен командалар туплауны оештыру.

**«МРҮ» ДУ** – массакүләм мәгълүмат чараларында ярышлар барышын һәм нәтиҗәләрен яктырту.

**«Форпост»** – ярышлар вакытында куркынычсызлыкны тәэмин итү.

## 5. Ярышлар программасы һәм үткәрү тәртибе.

***Ярышлар Олимпия системасы буенча үткәрелә.*** *Барлык ярышлар да бинадан тыш үткәрелә. Ярышлар вакыты оештыру комитеты тарафыннан килештерелә (һава торышы шартлары белән бәйле).*

## СПАРТАКИАДАНЫ АЧУ

**Үткәрү вакыты:** 2021 елның 6 феврале

**Үткәрү урыны:** «Кояшлы Ык» яр буе (Чаңгы базасы), Спорт мәктәбе.

## БИАТЛОН

**Үткәрү вакыты:** 2021 елның 6 феврале
**Үткәрү урыны:** «Кояшлы Ык» яр буе (Чаңгы базасы), Спорт мәктәбе.
**БИАТЛОН:** Катнаш эстафета (2 хатын-кыз + 2 ир, 1 км – хатын-кызлар, 1 км – ир-атлар) – «Кояшлы Ык» яр буе. Биатлон эстафетасында беренче катнашучылар судья командасыннан соң, катнашучы командалар санына карап, «бергә яисә 30 секунд вакыт интервалы» белән старт ала. Билгеле бер дистанция узганнан соң (450 метр) һәр спортчыга басып биш мишеньга ату кирәк булачак (мишень диаметры 10 см, ату дистанциясе 10 метр). Тидерә алмаган очракта өч өстәмә патрон кулланырга мөмкин. Ярышлар барышында спортчыларга түгәрәк мәйданны кисү, бер-берсенә аңлы физик йогынты ясау тыела. Биатлон кагыйдәләре катнашучыларга шулай ук чит мишеньгә атуны тыя. Спортчының чит мишеньгә төгәл элгүе тидерә алмау дип санала. Ярышның җиңүчесе булып дистанциядә иң яхшы вакыт күрсәткән команда танылa. Пневматик винтовканы (бер разрядлы) команда үзе белән алып килә.

## Киез итекләр футболы
## (ВАЛЕНКОБОЛ)

**Үткәрү вакыты:** 2021 елның 13 феврале
**Үткәрү урыны:** «Юность» спорт-сәламәтләндерү комплексы
**Валенкобол:** Команда составы: 5 уенчы (4 уенчы, 1 капкачы) + запас уенчылар. Ярышлар җирәбә салу буенча үткәрелә. Капкачы тупны ыргытканда мәйданның үз яртысыннан чыгарырга тиеш түгел. Әгәр туп капкачы тарафыннан мәйданчыкның икенче яртысына ташланса, туп көндәш командасына күчә.

## АРКАН ТАРТУ

**Үткәрү вакыты:** 2021 елның 21 феврале
**Үткәрү урыны: УСЗ керү юлы янында**
**АРКАН ТАРТУ (ир-атлар):** Команда составы – 5 кеше. Гомуми авырлык 450 кг.га кадәр. Командалар арасында ярыш өч омтылыштан тора. Командаларның берсе ике омтылышта җиңү яулаган очракта, өченчесе үткәрелми. Һәр омтылыштан соң командалар урыннар белән алыша һәм ял итә (ике минуттан да артык түгел).

**АРКАН ТАРТУ (хатын-кызлар):** Команда составы – 5 кеше. Гомуми авырлык 400 кг.га кадәр. Командалар арасында тартыш өч омтылыштан тора. Командаларның берсе ике омтылышта җиңү яулаган очракта, өченчесе үткәрелми. Һәр омтылыштан соң командалар урыннар белән алыша һәм ял итә (ике минуттан да артык түгел).

## ШОРТ-ТРЕК

**Үткәрү вакыты:** 2021 елның 21 феврале
**Үткәрү урыны: «Юность» спорт-сәламәтләндерү шугалагы**
**Шорт-трек** (эстафета, 2 ир-ат + 1 хатын-кыз: «Юность» спорт-сәламәтләндерү комплексы; ир-атлар – 800 м, хатын-кызлар – 400 м.

## СУПЕРФИНАЛ

**Үткәрү урыны:** «Юность» спорт-сәламәтләндерү комплексы, УСЗ, чаңгы базасы.
**Үткәрү вакыты:** 27.02.20021 ел – 9:00 сәг.
**СУПЕРФИНАЛ:** оешмалар, предприятиеләр һәм авыл җирлекләре арасында гомумкоманда зачетында 1 урынны алган командалар катнашачак. Ярышларның барлык төрләре дә бер көнне узачак. Суперфиналда барлыгы 5 спорт төре узачак.

**Болар – биатлон, киез итекләрдә футбол, аркан тарту (хатын - кызлар һәм ир-атлар), шорт-трек.**

**Әлеге Нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора!**

Белешмәләр өчен телефон: 2-59-48

**Гариза үрнәге**
**Мөслим муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре арасында**
**XXI кышкы спартакиадада катнашучы**
**__________________________ командасы.**

**________________________ (спорт төре)**

«___» ___________2021 ел.
Мөслим

| № | Ф.И.О. (тулысынча) | Туган елы | Эш урыны | Табиб визасы | Табиб имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |

Рөхсәт бирелде: _____________ кеше.
Табиб: _____________.

Команда вәкиле _______ /________/
Учреждение башлыгы ___________ /______________/

2.1 кушымта

**О е ш м а л а р  һ ә м  п р е д п р и я т и е л ә р  а р а с ы н д а**
**X X X I  к ы ш к ы  с п а р т а к и а д а**

**о ч к о л а р ы н   и с ә п л ә ү**
**Т А Б Л И Ц А С Ы**

| Урын – очко | Урын – очко | Урын – очко |
|---|---|---|
| 1 - 80 | 8 - 51 | 15 - 37 |
| 2 - 75 | 9 - 48 | 16 - 36 |
| 3 - 70 | 10 - 45 | 17 - 35 |
| 4 - 65 | 11 - 43 | 18 - 34 |
| 5 - 60 | 12 - 41 | 19 - 33 |
| 6 - 57 | 13 - 39 | 20 - 32 |
| 7 - 54 | 14 - 38 | 21 - 31 |